**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ТЕЛӘЧЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ АЛАН АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**
**(IV чакырылыш)**

# КАРАРЫ

**уналтынчы утырыш**

**«12» май 2022 ел** **№ 73** **Алан авылы**

**Теләче муниципаль районы Алан авыл җирлеге Советының 2017 елның 5 нче октябрендәге 59 нчы номерлы «Теләче муниципаль районы Алан авыл җирлеге Башкарма комитеты җитәкчесенең һәм аның гаилә әгъзаларының керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүматларны "Интернет" челтәрендәге Теләче муниципаль районының рәсми сайтында урнаштыру һәм әлеге мәгълүматларны массакүләм мәгълүмат чараларына бастырып чыгару өчен бирү тәртибе турында Нигезләмәне хакында» карарына үзгәрешләр кертү турында**

Теләче районы прокуратурасының 2022 елның 17 мартындагы №02-03-01-2022 номерлы протестын карап, «Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2021 елның 30 декабрендәге 471-ФЗ номерлыФедераль закон нигезендә, Теләче муниципаль районы Алан авыл җирлеге Советы карар итте:

1.Теләче муниципаль районы Алан авыл җирлеге Советының 2017 елның 5 нче октябрендәге 59 нчы номерлы «Теләче муниципаль районы Алан авыл җирлеге Башкарма комитеты җитәкчесенең һәм аның гаилә әгъзаларының керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүматларны "Интернет" челтәрендәге Теләче муниципаль районының рәсми сайтында урнаштыру һәм әлеге мәгълүматларны массакүләм мәгълүмат чараларына бастырып чыгару өчен бирү тәртибе турында Нигезләмәне хакында» карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) күрсәтелгән карар белән расланган Теләче муниципаль районы Алан авыл җирлеге Башкарма комитеты җитәкчесенең һәм аның гаилә әгъзаларының керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүматларны "Интернет" челтәрендәге Теләче муниципаль районының рәсми сайтында урнаштыру һәм әлеге мәгълүматларны массакүләм мәгълүмат чараларына бастырып чыгару өчен бирү тәртибе турында Нигезләмәгә:

– 2 пунктның "г" пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«г) җир кишәрлеге, башка күчемсез милек объекты, транспорт чарасы, кыйммәтле кәгазьләр, акцияләр (оешмаларның устав (туплау) капиталларында катнашу өлеше, пайлары), санлы финанс активлары, цифрлы валюта сатып алу буенча килешүләр (алыш-бирешләр башкарылган) акча алу чыганаклары турында белешмәләр, әгәр мондый алыш-бирешләрнең гомуми суммасы Теләче муниципаль районы Алан авыл җирлеге Башкарма комитеты җитәкчесенең һәм аның хатынының (иренең) гомуми керемннән артып китә икән, хисап чорына кадәрге соңгы өч ел эчендә.».

2. Әлеге карарны гамәлдәге законнар нигезендә бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карар гамәлдәге законнар нигезендә үз көченә керә.

Алан авыл җирлеге башлыгы Б.Н. Хәсәнов